Республика Татарстан
Глава Монашевского сельского поселения
Менделеевского муниципального района
423644, Менделеевский район,
с. Монашево,
ул. Школьная, д 19

Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районы
Монашево авыл җирлеге Башлыгы
423644, Менделеевск районы,
Монашево авылы,
Мәктәп урамы, 19 й.

тел./факс 8/85549/3-73-18,
E-mail: Mon.Men@tatar.ru, http://mendeleevsk.tatarstan.ru/rus/monashevskoe-selskoe-poselenie.htm

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

01.11.2025 ел № 6

Татарстан Республикасы Менделеевск
муниципаль районы Монашево авыл
җирлегенең  Монашево авылында
гражданнарның үзара салым акчаларын
кертү һәм куллану мәсьәләләре буенча
гражданнар җыенын билгеләү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы  Монашево авыл җирлеге  Уставының 22 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы “Монашево авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге башлыгы
КАРАР БИРӘ:

1. 2025 елның 14 ноябре 15.00 сәг. гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләләре буенча гражданнар җыенының беренче этабын билгеләргә.
2.  2025 елның 14 ноябре 16.00 сәг. гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләләре буенча гражданнар җыенының икенче этабын билгеләргә.
3. 2025 елның 14 ноябре 17.00 сәг. гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләләре буенча гражданнар җыенының өченче этабын билгеләргә.

4. Барлык этапларны уздыру урыны итеп Менделеевск районы, Монашево авылы, Ленин ур., 18 йорт абдесы буенча Монашево авыл мәдәният йортын билгеләргә.
5. Монашево авылында яшәүчеләр исемлеген җыен этапларына бүлүне территориаль билге буенча түбәндәге тәртиптә башкарырга:

Беренче  этап: Мәктәп ур,  1-31 й., Яңа ур.,  1-9 й.,
Икенче  этап: Ленин ур.,  1-52 й.
Өченче  этап: Михаил Петров ур., 1-19 й., Елга аръягы ур.,  1-9 й..

6. "Менделеевск муниципаль районы Монашево авыл җирлегенең Монашево авылында яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, I-II төркем инвалидлардан, махсус хәрби операциядә катнашучылардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, 2026 елда үзара салымны 1000 сум күләмендә кертүгә Сез ризамы?” дигән сорауны расларга.
1) Монашево торак пункты чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (юлларны кардан чистарту) ;

2) Монашево торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү (үлән чабу,шартнамә буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен);
3) Монашево торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү (карт агачларны кисү, шартнамә буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен);
4) Монашево янгынга каршы төзү, ремонтлау резервуарлар (янгын сулыклары), янгын пирслары(янгын пирсы документациясен рәсмиләштерү)?»

« РИЗА» «КАРШЫ»

7. Әлеге карарны кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә Монашево авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында (http://mendeleevsk.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

8. Әлеге карар игълан ителү көненнән үз көченә керә.

Монашево авыл җирлеге башлыгы Р.Ф. Иосифов